ГЛАВА
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

31.01.2019 г.Мензелинск № 8

2003 елның 6 октябрендәге "Җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында"гы №131 ФЗ нигезендә, 2018 елның 19 декабрендә узган Минзәлә муниципаль районында Терроргa каршы тору комиссиясе утырышы Беркетмәсенең 19 пунктын үтәү өчен

КАРАР ЧЫГАРАМ:

1. Терроризм һәм экстремизмны булдырмау буенча мәгълүмати-пропаганда төркеме оештыру.
2. Терроризм һәм экстремизмны булдырмау буенча мәгълүмати-пропаганда төркеме турындагы нигезләмәне расларга (Кушымта №1).
3. Терроризм һәм экстремизмны булдырмау буенча мәгълүмати-пропаганда төркеме составын расларга (Кушымта №2).
4. Гамәлдәге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Минзәлә муниципаль район Советы Аппараты Җитәкчесе Э.В.Хәбибуллинага йөкләргә.

Башлык А.Ф. Салахов

Минзәлә муниципаль
район Башлыгы
Карарына
Кушымта №1
дата 31.01.19 № 8

Терроризмны һәм экстремизмны профилактикалау буенча
мәгълүмати-пропаганда төркеме турында
НИГЕЗЛӘМӘ

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1.Терроризмга һәм экстремизмга каршы тору өлкәсендә дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында тулы һәм дөрес мәгълүмат алуга гражданнарның конституцион хокукларын тормышка ашыру максатларында, шулай ук террористик һәм экстремистик эшчәнлекнең җәмгыятькә каршы асылын Минзәлә муниципаль район халкына компетентлы аңлату, район территориясендә җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итүдә актив катнашуга гражданнарны мобилизацияләү өчен, Минзәлә муниципаль районында терроризм һәм экстремизмны профилактикалау буенча мәгълүмати-пропаганда төркеме (алга таба - мәгълүмати-пропаганда төркеме) оештырыла.

1.2.Мәгълүмати-пропаганда төркеме Россия Федерациясе Контитуциясен, федераль законнарны, Россия Федерациясе Президенты әмерләрен һәм күрсәтмәләрен, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларын һәм күрсәтмәләрен, Татарстан Республикасы законнарын һәм норматив-хокукый актларын, җирле үзидарә органнарының норматив-хокукый актларын, шулай ук гамәлдәге Нигезләмәне үз эшчәнлегендә куллана.

1.3.Террорга каршы милли комитет һәм Татарстан Республикасында террорга каршы комиссия карарлары мәгълүмати-пропаганда төркеме өчен мәҗбүри булып тора.

## II. Мәгълүмати-пропаганда төркеме бурычлары

2.1. Минзәлә муниципаль район территориясендә терроризмга һәм экстремизмга каршы тору өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыруда катнашу.

2.2. Терроризмга һәм экстремизмга каршы тору өлкәсендәге вәзгыятькә тәэсир итүче Минзәлә муниципаль районының сәяси, социаль-икътисадый һәм башка процесслар мониторингы.

2.3. Массакүләм мәгълүмат чараларында мәгълүмати-пропаганда материалларын әзерләү һәм алга җибәрү.

2.4. Иҗтимагый һәм дини оешмаларга тынычлыкны һәм килешүне ныгыту максатларында милләтара һәм конфессияара диалогны, толернатлыкны үстерүгә юнәлтелгән мәдәни-агарту чараларын һәм проектларны тормышка ашырганда уңай шартлар тудыру.

2.5. Терроризмны, экстремизмны профилактикалау, аларның килеп чыгу нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм юкка чыгару өлкәсендә Минзәлә муниципаль районы оешмалары һәм иҗтимагый берләшмәләре арасында үзара бәйләнеш булдыру.

2.6. Дини-сәяси экстремизм идеологиясенең җинаятьчел асылын аңлату максатларында Интернет челтәрендә даими максатчан эш оештыру.

2.7. Терроризмны, экстремизмны профилактикалау, аларның килеп чыгу нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм юкка чыгару өлкәсендә башка мәсьәләләрне Россия Федерациясе законнарында каралганча хәл итү.

2.8. Террористик һәм экстремистик идеология таратуны профилактикалау. Терроризм һәм экстремизмның җәмгыятькә каршы асылын халыкка аңлату.

2.9. Терроризмга һәм экстремизмга каршы тору буенча уздырыла торган дәүләт сәясәтенең төп юнәлешләре турында халыкка мәгълүмат бирү.

2.10. Террорга һәм экстремизмга каршы юнәлтелгән материалларны массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту.

2.11. Халыкның радикальләшү дәрәҗәсен киметү һәм террористик һәм экстремистик идеология таралуга алшартларны юкка чыгару өчен шартлар тудыру.

2.12. Россия җәмгыятенең терроризм килеп чыгу, таралу сәбәпләрен һәм шартларын киметүче яисә бетерүче мәдәни, әхлакый һәм мәгариф потенциалын күтәрү.

2.13. Террористик күренешләр сәбәбе булырдай этно-конфессиональ каршылыклы ситуацияләргә мәгълүмати тәэсир итү.

2.14. Мәгълүмати янау күренешләренә каршы тору:

- халыкның террористик янауга уяулыгын күтәрү һәм террористик күренешләрне кисәтү эшендә хокук саклау органнары һәм махсус хезмәтләр белән актив хезмәттәшлек итү зарурлыгы;

- Россия Федерациясе дәүләт сәясәте кысаларында яшьләр белән терроризмга каршы тору буенча тәрбияви эш алып бару.

2.15. Террористик һәм экстремистик күренешләр сәбәбе булырдай этноконфессиональ конфликтлы ситуацияләрне локальләштерү буенча чараларда катнашу.

2.16. Халыкның террористик янауга уяулыгын күтәрүгә ярдәм итү һәм

террористик һәм экстремистик күренешләрне булдырмау эшендә хокук саклау органнары һәм махсус хезмәтләр белән актив хезмәттәшлекне башлап җибәрү:

- терроризм һәм экстремизм килеп чыгу белән бәйле ситуацияләргә оператив мәгълүмати җавап кайтару буенча комплекслы чараларны эшкәртү һәм аларны башкару;

- террорга каршы һәм экстремистик юнәлештәге агарту чараларын уздыру өчен методик ярдәмлекләр әзерләү.

## III. Мәгълүмати-пропаганда төркеменең эш тәртибе

3.1. Төркем җитәкчесе:

- төркем эшчәнлеген оештыра һәм координацияли;
- төркем утырышларын билгели;
- төркем беркетмәләрен һәм карарларын имзалый.

3.2. Төркем җитәкчесе урынбасары эш төркеме җитәкчесе булмаганда яисә аның йөкләмәсе буенча төркем җитәкчесе вазифаларын башкара.

3.3.Төркем сәркатибе:

- төркем утырышы беркетмәләрен алып бара һәм имзалый;
- төркем әгъзаларына утырыш узу вакытын һәм урынын хәбәр итә;
-төркемгә керүчеләрнең материаллары һәм мөрәҗәгатьләре учетын алып бара.

3.4. Утырышларның уздыру сроклары һәм көн тәртибе төркем әгъзаларына утырышка кадәр 5 көннән соңармыйча хәбәр ителә.

3.5. Төркем утырышлары кимендә кварталга 1 тапкыр уздырыла һәм әгәр анда эшче төркем әгъзаларының яртысы катнаша икән, тулы хокуклы санала.

3.6. Утырышта катнашучы төркем әгъзаларының күбесе хуплаган очракта, төркем карарлары кабул ителгән дип санала.

3.7. Кабул ителгәннән соң бер атна эчендә карарлар кызыксынган оешмаларга җибәрелә.

3.8. Төркем карарлары тәкъдим итү характерында була.

## IV. Мәгълүмати-пропаганда төркеме хокуклары.

Үз бурычларын үтәү өчен мәгълүмати-пропаганда төркеме түбәндәгеләргә хокуклы:

4.1.Терроризмны профилактикалау, аның килеп чыгу нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм ликвидацияләү буенча территориаль органнарның, башкарма хакимиятнең федераль органнарының, башка дәүләт органнарының, оешмаларның һәм иҗтимагый оешмаларның, җирле үзидарә органнарының үзара бәйләнешен оештыру, координацияләү һәм камилләштерүгә кагылышлы

карарларны үз компетенцияләре чикләрендә кабул итәргә.

4.2.Терроризмны һәм экстремизмны профилактикалау мәсьәләләре буенча тәкъдимнәрне билгеләнгән тәртиптә кертергә.

4.3.Төркем үз эшчәнлеген планлы нигездә башкара. Төркемнең эш планы Минзәлә муниципаль районында Террорга каршы тору комиссиясе Рәисе тарафыннан раслана.

4.4.Төркем Минзәлә муниципаль районында террорга каршы комиссияне үз эшчәнлеге нәтиҗәләре белән таныштыра.

4.5.Төркем эше нәтиҗәләре буенча Минзәлә муниципаль районында террорга каршы комиссия билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасындагы Террорга каршы комиссиягә мәгълүмат бирә:

- Минзәлә муниципаль районының рәсми порталында мәгълүмати хәбәрләр һәм материаллар урнаштыру;

- Минзәлә муниципаль районындагы террорга каршы тору комиссиясе әгъзалары, Минзәлә муниципаль район учреждениеләре һәм предприятиеләре җитәкчеләре, чакырылган экспертлар һәм белгечләр, депутат корпусы, иҗтимагый оешмалар, дини берләшмәләр катнашында массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре һәм җәмәгатьчелек өчен очрашулар, персс-конференцияләр, брифинглар, презентацияләр, "түгәрәк өстәлләр" оештыру;

- Минзәлә муниципаль районында террорга каршы тору комиссиясе әгзаларын җәмәгатьчелек каршында, закон чыгаручы органнарның депутатлары, хакимият органнарында эшләүчеләр каршында, предприятиеләрдә, иҗтимагый һәм белем бирү оешмаларында чыгыш ясауга җәлеп итү;

- терроризмга каршы торуга багышланган конференцияләр, форумнар, фестивальләр, конкурслар, күргәзмәләр, экспозицияләр оештыру;

- терроризмга каршы тору проблемалары буенча китаплар, монография, мәкаләләр, документлар җыентыгы һ.б.лар әзерләүдә тикшеренүләр өстендә эшләүдә фәнни һәм иҗади берләшмә вәкилләренә ярдәм күрсәтү;

- террорга каршы юнәлештәге тышкы реклама һәм күрсәтү-агитация продукциясе чараларын (плакат, листовка, календарь һ.б.лар) әзерләү инициативасын башларга.

Минзәлә муниципаль
район Башлыгы
Карарына
Кушымта №2
дата 31.01.18 № 8

**Минзәлә муниципаль районында терроризмны һәм экстремизмны профилактикалау буенча мәгълүмати-пропаганда төркеме**
СОСТАВЫ

1. Хәбибуллина Э.В. – Минзәлә муниципаль район Советы Аппараты җитәкчесе – эш төркеме рәисе.
2. Токарев М.О. – Минзәлә муниципаль район Башлыгы Ярдәмчесе – эш төркеме рәисе урынбасары.
3. Ворожцова Е.В. – Минзәлә муниципаль район Башкарма комитетының балигъ булмаганнар эше буенча комиссиянең баш белгече – комиссия сәркатибе.

Төркем әгъзалары:

4. Бикеева Н.Г. – Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсәләләр буенча урынбасары.
5. Баскова С.И. – Минзәлә муниципаль район Башкарма комитетының Гомуми бүлек начальнигы.
6. Хафизова Н.А. – Минзәлә муниципаль район Башкарма комитетының мәгариф бүлеге Җитәкчесе урынбасары.
7. Заместитель Руководителя отдела образования Исполнительного комитета Мензелинского муниципального района.
8. Михайлова И.М. – «Веста» Яшьләр үзәге җитәкчесе.
9. Волощенко Н.К. – Минзәлә шәһәренең 4 нче ТОС җитәкчесе.
10. Хәлимова Г.К. – Минзәлә районы Иҗтимагый Советы җитәкчесе.
11. Храмутичев Р.Ю. – Никольский кафедраль соборы настоятеле (килешенү буенча)
12. Харрасов З.Г. – Минзәлә район имам-мөхтәсибе (килешенү буенча)
13. Шаһиев И.И. – "Татмедиа" АҖ филиалы җитәкчесе (килешенү буенча).